


2024 елнын 5 апрелендә Татарстан Республикасынын Лениногорск шәһәрендәге Ш.М.Бикчурин исемен йорткән дvртенче урта мәктәбендә икенче зона фәнни-гамәли конференциясе vткән.
Бу конференциядә Рузаевка районы Шәриф Камал исемендәге Татар Пешлә урта мәктәбе укучылары, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сания Спартак кызы Саляева житәкчелегендә катнаштылар һәм тvбәндәге унышларга ирештеләр:      Оченче сыйныф укучысы Гурина Әминә, vзе ижат иткән “Минем гаиләм” дигән шигыре белән 1 урын, ә 7сыйныф укучысы Гундина Камилә vзенен ижат жимеше - “Яз башы” шигыре белән лауреат һәм житәкчеләре Сания Спартаковна да беренче урын яулап, грамоталар белән бvләкләнделәр.
Бу мәктәпнен унышлары байтак. Шулай, 2024 елнын 12 апрелендә Саранскида «Ин яхшы мәктәп ашханәсе-2024» дәрәжәле Ботенроссия конкурсынын тобәк этабы узды. Республиканын 15 мәгариф учреждениесе - жиде мәктәп командасы «Авыл мәктәбенен ин яхшы ашханәсе» номинациясендә, 8 команда «Шәһәр мәктәбенен ин яхшы ашханәсе» номинациясендә коч сынашты.
Призлы урынны лаеклы Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе яулады.
Конкурска алар татар милли ризыклары: токмач, азу, очпочмак, кыстыбый, киптерелгән жиләк-жимеш белән татлы плов кертелгән тематик остәл тәкъдим иткәннәр. Конкурска тәкъдим ителгән ризыкларнын һәр компоненты файдалы vзлекләргә ия, алар бергәләп витаминнар, микроэлементлар чыганагын тәшкил итә һәм кон дәвамында энергияне сак-лауга һәм vсеп килvче организмнын дорес vсешенә ярдәм итә.